**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**Авиация һәлакәте белән бәйле рәвештә матәм көне игълан итү турында**

2021 елның 10 октябрендә Татарстан Республикасы Минзәлә районында авиация һәлакәте сәбәпле фаҗигате рәвештә кешеләр һәлак булуы белән бәйле рәвештә, һәлак булганнар турында авыр кайгы белдереп, аларның туганнары һәм якыннарының хәсрәтен уртаклашып, **карар бирәм:**

1. 2021 елның 11 октябрен Татарстан Республикасында матәм көне дип игълан итәргә.

2. Матәм көнендә Татарстан Республикасының бөтен территориясендә Татарстан Республикасы Дәүләт флагларын түбәнрәк төшерергә.

3. Телерадиокомпанияләргә һәм мәдәният учреждениеләренә матәм көнендә күңел ачу тапшыруларын һәм чараларын үткәрмәүне тәкъдим итәргә.

4. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына авиация һәлакәте нәтиҗәсендә һәлак булганнарның гаиләләренә һәм зыян күрүчеләргә ярдәм итү буенча тәкъдимнәр әзерләргә.

5. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ • АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2021 ел, 10 октябрь
№ ПУ-804